КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 12 март г.Казань № 124

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{20}$ статьясы белән күздә тотылган очракларда Татарстан Республикасы милкендәге яки аларга карата дәүләт милке чикләнмәгән, аларда биналар, корылмалар урнашкан җир кишәрлекләрен мондый биналар, корылмалар йә алардагы бүлмәләр милекчеләренә сату турында» 2012 ел, 3 октябрь, 827 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{20}$ статьясы белән күздә тотылган очракларда Татарстан Республикасы милкендәге яки аларга карата дәүләт милке чикләнмәгән, аларда биналар, корылмалар урнашкан җир кишәрлекләрен мондый биналар, корылмалар йә алардагы бүлмәләр милекчеләренә сату турында» 2012 ел, 3 октябрь, 827 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 15 февраль, 105 нче; 2015 ел, 10 март, 138 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{4}$ статьясы, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{20}$ статьясы белән күздә тотылган очракларда Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә карата торглар үткәрмичә җир кишәрлеген сату-сатып алу шартнамәсен төзегәндә җир кишәрлегенең, әлеге карарның 2 пунктында билгеләнгән очраклардан тыш, мондый җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма яисә алардагы бүлмәләр милекчесе мөрәҗәгате кергән вакытка гамәлдә булган җир кишәрлегенең 100 процент кадастр кыйммәте күләмендә билгеләнә.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{20}$ статьясы белән күздә тотылган очракларда җир кишәрлекләрендә урнашкан биналар, төзелмәләр яисә алардагы бүлмәләрнең бу карар үз көченә кергәнгә кадәр җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзегән милекчеләренә сатканда Татарстан Республикасы милкендәге яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре (алга таба – җир кишәрлекләре) кыйммәтен билгеләгәндә кулланыла торган җир бәясе 2024 елның 1 гыйнварына кадәр түбәндәгеләрне тәшкил итә:

халык саны 500 мең кешедән артык булган Татарстан Республикасы торак пунктларында – җир кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен җир салымының 17 ставкасы күләмендә;

халык саны 500 мең кешегә кадәр булган Татарстан Республикасы торак пунктларында – җир кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен җир салымының 10 ставкасы күләмендә;

торак пунктлар чикләреннән читтә – җир кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен җир салымының өч ставкасы күләмендә;

2024 елның 1 гыйнварына кадәр әлеге карар үз көченә кергәнгә кадәр Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^{3}$ статьясы нигезендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен торглар үткәрмичә бирелгән җир кишәрлекләренең кыйммәте инвестиция проектын тулысынча гамәлгә ашыру шарты белән әлеге пунктның өченче – бишенче абзацларында каралган күләмнәрдә билгеләнә;

биналар, төзелмәләр, корылмалар милекчеләре үзләрендә арендада булган җир кишәрлекләрен җир кишәрлеге кадастр кыйммәтенең 2,5 процентка тигез булган бәядән түбәндәге очракларда сатып ала:

«Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 137-ФЗ номерлы Федераль закон) үз көченә кергән көннән 2012 елның 1 июленә кадәр әлеге җир кишәрлекләренә карата аренда хокукына даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын яңадан рәсмиләштерү гамәлгә ашырылганда;

әлеге җир кишәрлекләре 137-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көннән 2012 елның 1 июленә кадәрге чорда аренда хокукына даими (вакыты чикләнмәгән) куллану хокукын яңадан рәсмиләштерү гамәлгә ашырылган җир кишәрлекләреннән барлыкка килә.

3. Җирле үзидарә органнарына муниципаль милектәге җир кишәрлекләренең бәяләрен билгеләгәндә әлеге карар нигезләмәләренә таянып эш итүне тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милкендәге яки аларга карата дәүләт милке чикләнмәгән, аларда урнашкан биналар, төзелешләр, корылмалар милекчеләренә аерып бирелә торган җир кишәрлекләрен сату турында» 2012 ел, 3 октябрь, 827 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 ел, 15 февраль, 105 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милкендәге яки аларга карата дәүләт милке чикләнмәгән, аларда урнашкан биналар, төзелешләр, корылмалар милекчеләренә аерып бирелә торган җир кишәрлекләрен сату турында» 2012 ел, 3 октябрь, 827 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 10 март, 138 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин